**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ «ИСКЕ ДӨРЕШ» АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»**
**МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ СОВЕТЫ**

«22» май 2020 ел № 3/3

# КАРАР

**«Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Иске Дөреш авыл җирлеге Советының муниципаль хезмәт турында нигезләмәсен раслау хакында» Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Иске Дөреш авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Советының 2019 елның 30 январендәге 1/2 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында**

«Россия Федерациясе Хезмәт Кодексына хезмәт эшчәнлеге турында мәгълүматларны электрон рәвештә формалаштыру өлешендә үзгәрешләр кертү хакында» 2019 елның 16 декабрендәге 439-ФЗ номерлы, «Коррупциягә каршы тору турында Россия Федерациясе законнарын камилләштерү максатында Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2019 елның 16 декабрендәге 432-ФЗ номерлы Федераль законнар, «Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексы» 2013 елның 25 июнендәге 50-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә Тукай муниципаль районы Иске Дөреш авыл җирлеге Советы

**КАРАР БИРДЕ:**

1. «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Иске Дөреш авыл җирлеге Советының муниципаль хезмәт турында нигезләмәсен раслау хакында» Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Иске Дөреш авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Советының 2019 елның 30 январендәге 1/2 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 8 статьяның 8.22 пунктында «һәм хезмәт кенәгәсенә» сүзләрен «хезмәт кенәгәсенә һәм (яки) хезмәт эшчәнлеге турында мәгълүматларга» дигән сүзләргә алыштырырга;

1.2. 29 статьяның 29.2 пунктын яңа редакциядә бәян итәргә:

«29.2. Муниципаль хезмәткәр әлеге нигезләмәнең 12 һәм 15 статьяларында каралган хокук бозулар кылган очракларда, ышаныч югалу сәбәпле, муниципаль хезмәттән азат ителергә тиеш.»

1.3. 29 статьяның 29.2 пунктын яңа редакциядә бәян итәргә:

«29.3. Әлеге нигезләмәнең 12, 15 һәм 28 статьяларында каралган шелтә белдерү эшкә алучы вәкиле (эш бирүче) тарафыннан түбәндәгеләр нигезендә кулланыла:

1) коррупцион һәм башка хокук бозуларны профилактикалау буенча тиешле муниципаль органның кадрлар хезмәте бүлекчәсе (алга таба - хокук бозуларны

профилактикалау буенча кадрлар хезмәте бүлекчәсе) үткәргән тикшерү нәтиҗәләре турында доклад;

2) тикшерү нәтиҗәләре турында доклад комиссиягә җибәрелгән очракта, муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт тәртибе таләпләрен үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча комиссия тәкъдимнәре;

2.1) коррупцион хокук бозуларны профилактикалау буенча кадрлар хезмәте бүлекчәсенең коррупцион хокук бозу турында докладьı, анда аны башкаруның факттагы шартлары бәян ителә, һәм муниципаль хезмәткәрнең бары тик аның ризалыгы белән генә һәм коррупцион хокук бозу фактын тану шарты белән муниципаль хезмәткәрнең язма аңлатмасы (ышаныч югалуга бәйле рәвештә, эштән азат итү рәвешендә җәза кулланудан тыш);

3) муниципаль хезмәткәр аңлатмалары;

4) башка материаллар.».

1.4. 30 статьяның 4 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

4) муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт кенәгәләрен һәм (яки) хезмәт эшчәнлеге турында мәгълүматларны алып бару.

2. Әлеге карарны Тукай муниципаль районының рәсми сайтында (http://tukay.tatarstan.ru), Татарстан Республикасы рәсми хокукый порталында (http://pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны законлылык, хокук тәртибе, милли мәсьәләләр һәм халык куркынычсызлыгы буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Муниципаль берәмлек Башлыгы,
Совет Рәисе Р.М. Дусадбеков